**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЗУР КУККУЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАРЫ

2023 елның 3 августы № 104

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Зур Куккуз авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең коррупциячел хокук бозуларны кылган өчен җаваплылыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " 2023 елның 13 июнендәге 258- ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Зур Куккуз авыл җирлеге Советының 2012 елның «03” ноябрендәге 19 номерлы карары белән расланган коррупциячел хокук бозулар кылган өчен Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Зур Куккуз авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2.4 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«яллаучының вәкиле булган муниципаль хезмәткәрнең үзенә буйсынган муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында билгеле булган муниципаль хезмәткәрләргә, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу буенча чаралар күрү;».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирлек башлыгына йөкләргә.

**Зур Куккуз**
**авыл җирлеге Башлыгы –**
**Зур Куккуз авыл җирлеге**
**Советы рәисе** **Р.Ф.Низамова**